ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.01.2015 Казан ш. № 10-1/кс

***2015 елга эчәргә яраклы суга һәм су агызуга тарифлар билгеләү турында***

“Эчәргә яраклы су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында” 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ санлы Федераль законга, “ Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында” 2013 елның 13 маендагы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, “2015 елга су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә гамәлдәге тарифларны үзгәртүнең мөмкин булган максималь чик индексларын уртача Россия Федерациясе субъект-лары буенча билгеләү турында” 2014 елның 11 октябрендәге 228-э/4 санлы тарифлар буенча Федераль хезмәт боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүче һәм су агызуны башкаручы оешмалар өчен эчәргә яраклы суга һәм су агызуга тарифларны, билгеле бер календарь чорларына бүлеп, әлеге карар кушымтасы нигезендә билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2015 елның 1 мартыннан 2015 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карар кушымтасында күрсәтелгән салкын су белән тәэмин итүче һәм су агызуны башкаручы оешмаларга Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 санлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән алып 30 календарь көннән дә соңга калмыйча халыкка җиткерелергә тиешле мәгълүматны ачарга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты карарына кушымта
23.01.2015 № 10-1/кс

2015 елга билгеле бер календарь чорларына
салкын су белән тәэмин итүче һәм су агызуны башкаручы оешмалар өчен
эчәргә яраклы суга һәм су агызуга тарифлар

| № п/п | Салкын су белән тәэмин итүче һәм (яисә) су агызуны башкаручы оешмалар, муниципаль берәмлекләр атамасы | Эчәргә яраклы суга тариф (бер ставкалы) сум/куб.м | | Су агызуга тариф (бер ставкалы) сум/куб.м | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2015 елның 1 мартыннан 2015 елның 30 июненә кадәр | 2015 елның 1 июленнән 2015 елның 31 декабренә кадәр | 2015 елның 1 мартыннан 2015 елның 30 июненә кадәр | 2015 елның 1 июленнән 2015 елның 31 декабренә кадәр |
| | Буа муниципаль районы | | | | |
| 1 | «Родник» ҖЧҖе | 22,37 | 23,71 | | |
| | Биектау муниципаль районы | | | | |
| 2 | «Биектау коммуналь челтәрләре» ААҖе, тарифларны технологик яктан үзара бәйләнмәгән берничә үзәкләштерелгән системаларга ия булуга бәйле дифференциацияләү | | | | |
| 2.1 | Авыл торак жире бакчачы кулланучылары | | | | |
| 2.1.1 | Халык (тарифлар НДСны исәпкә алып күрсәтелгән)* | 25,77 | 26,62 | 27,93 | 29,59 |
| 2.1.2 | Башка кулланучылар (тарифлар НДСтан тыш күрсәтелгән) | 21,84 | 22,56 | 23,67 | 25,08 |
| 2.2 | Чернышев авыл торак җире кулланучылары | | | | |
| 2.2.1 | Халык (тарифлар НДСны исәпкә алып күрсәтелгән)* | | | 27,93 | 29,59 |
| 2.2.2 | Башка кулланучылар (тарифлар НДСтан тыш күрсәтелгән) | | | 23,67 | 25,08 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 маддәсе 6 пунктын гамәлгә ашыру максатыннан чыгып бүлеп бирелә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитетының тарифлар буенча карарларны
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге